КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 13 март г.Казань № 179

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Мәдәни мирас объектларын саклау комитеты мәсьәләләре» 2018 ел, 12 июль, 565 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Мәдәни мирас объектларын саклау комитеты мәсьәләләре турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Мәдәни мирас объектларын саклау комитеты мәсьәләләре» 2018 ел, 12 июль, 565 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Мәдәни мирас объектларын саклау комитеты мәсьәләләре турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Комитет үз вәкаләтләрен гамәлгә ашырганда эшчәнлекнең билгеләнгән өлкәсендәге товар базарларында көндәшлекне үстерү максатлары һәм бурычлары өстенлеген тәэмин итә.»;

3.3 пунктта:

түбәндәге эчтәлекле 3.3.22[1] һәм 3.3.22[2] пунктчалар өстәргә:

«3.3.22[1]. Капиталь төзелеш объектының проект документлары бүлеген карап тикшерә һәм аның тарихый җирлекне саклау предметына һәм ФЗ-73 нче Федераль законның 60 статьясындагы 9 пункт нигезендә тарихый җирлек территориясе чикләрендә урнашкан территориаль зонага карата кулланыла торган шәһәр төзелеше регламенты белән билгеләнгән капиталь төзелеш объектларының архитектура

чишелешләренә карата таләпләргә туры килүе яки туры килмәве турында бәяләмә җибәрә;

3.3.22[2]. Индивидуаль торак төзелеше объектының яки бакча йортының тышкы кыяфәте тасвирламасын карап тикшерә һәм аның тарихый җирлекне саклау предметына һәм ФЗ-73 нче Федераль законның 60 статьясындагы 13 пункт нигезендә федераль әһәмияттәге яки төбәк әһәмиятендәге тарихый җирлек территориясе чикләрендә урнашкан территориаль зонага карата кулланыла торган шәһәр төзелеше регламенты белән билгеләнгән капиталь төзелеш объектларының архитектура чишелешләренә карата таләпләргә туры килүе яки туры килмәве турында бәяләмә җибәрә;»;

3.3.36 пунктчасында «текст һәм» сүзләрен төшереп калдырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин